**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«20» декабрь 2021 ел Мусабай-Завод авылы № 23

«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге җирләрен куллану һәм саклау» муниципаль программасын раслау турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклауны гамәлгә ашыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге җирләрен куллану һәм саклау» муниципаль программасын расларга (кушымта бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкчесе Башкарма комитет Ф. Ә. Әгъләҗева

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 20 декабрендәге 23 номерлы карарына кушымта

**«2021-2023 елларга**
**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Мусабай-Завод авыл җирлеге җирләрен куллану һәм саклау»**
**муниципаль программасы**

«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге җирләрен куллану һәм саклау» муниципаль программасы паспорты

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигез | РФ Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Заказчы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Заводавыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүче | Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаның төп максаты | Мусабай-Завод авыл җирлеге җирләрен саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чараларын гамәлгә ашыру |
| Программаның билгеләнеше | Мусабай-Завод авыл җирлеге җирләрен саклау мәсьәләләрен хәл итү |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2021 - 2023 еллар |
| Көтелгән нәтиҗәләр | Җирләрне саклау һәм рациональ файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, бозылган җирләрне торгызу, халыкның экологик куркынычсызлыгын һәм аның тормыш сыйфатын күтәрү |
| Программаны тормышка ашыруны контрольдә тоту | Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Программаны тормышка ашыру механизмы | Җирләрне саклау һәм алардан рациональ файдалану буенча хуҗаларның һәм кулланучыларның эшчәнлеген координацияләү Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла. Программага төзәтмәләр кирәк булганда кертелә |
| Финанслау чыганагы | Программаны үтәү муниципаль берәмлек бюджеты һәм оешма чаралары хисабына башкарыла |

1. Муниципаль программаны тормышка ашыруның тиешле өлкәсендә агымдагы торышы характеристикасы һәм төп проблемалар

Җир – әйләнә-тирә мохитнең мөһим өлеше, аны куллану башка табигать объектлары: хайваннар, урманнар, үсемлекләр дөньясы, сулар, файдалы казылмалар һәм башка җир асты байлыклары белән бәйле. Җирне кулланудан һәм саклаудан тыш башка табигый ресурслардан файдалану мөмкин түгел. Җиргә карата хуҗасызлык кичекмәстән яки якын киләчәктә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерәчәк, җирнең өске

катламы - туфрак җимерелүгә, аның химик һәм радиоактив пычрануына гына китереп калмыйча, бөтен табигать комплексының экологик начараюына китерәчәк.

«2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге җирләрен куллану һәм саклау» муниципаль программасы җирләрдән файдалану һәм саклауның икътисадны ныгыту мәнфәгатьләрендә җир ресурсларыннан нәтиҗәле һәм рациональ файдалану һәм алар белән идарә итү буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итүче уңай шартларын булдыруга юнәлтелгән.

Җир фондының зур күләмнәрен төрле максатларда куллану барлык әйләнә-тирә мохит экосистемасы звеноларының табигый бөтенлеген саклау буенча билгеле бер бурычлар йөкли. Табигатьтә барысы да үзара бәйләнгән. Шуңа күрә бер звеноның дөрес эшләвен бозу, урман булсынмы ул, хайваннар дөньясы, җир булсынмы, экосистеманың дисбалансына һәм бөтенлеген бозуга китерә.

Җирне рациональ файдаланмау, аңа карата кулланучы һәм хуҗасыз мөнәсәбәт ул башкара торган функцияләр бозылуга, табигый үзлекләренең кимүенә китерә.

Җирләрне саклау җирдән рациональ файдалану булганда гына нәтиҗәле булырга мөмкин.

Мусабай-Завод авыл җирлегенең тотрыклы социаль-икътисадый үсеше һәм аның халкының экологик яктан имин яшәү проблемалары хәзерге этапта җирләрне саклау һәм файдалану мәсьәләләрен хәл итү белән тыгыз бәйләнгән. Авыл җирлеге дәрәҗәсендә җирләрне саклау һәм куллану буенча җирле проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә мөмкин, өстәвенә, хәзер яшәүче кешеләр генә түгел, киләчәк буын мәнфәгатьләрендә тулы, комплекслы һәм уйлап эш итәргә мөмкин.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод давыл җирлеге территориясендә төрле рөхсәт ителгән файдаланудагы җир кишәрлекләре бар.

Авыл хуҗалыгы җирләренә караган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр аеруча кыйммәткә ия.

Җирлек территориясендәге көтүлекләр культура-техник торышы буенча нигездә чиста. Көтүлекләр шәхси ярдәмче хуҗалыклар тарафыннан файдаланыла.

Барлык көтүлек азыгын кулланучыларны исәпкә алып та, табигый көтүлекләргә зур зыян килми. Җирлекнең барлык көтүлекләрендә дә диярлек яшел үлән артыгы белән җитә.

Җирләрнең экологик торышы уртача яхшы, әмма стихияле рөхсәт ителмәгән чүплекләр әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый һәм экологик хәлне катлауландыра.

## 2. Муниципаль программаны тормышка ашыруның максатлары, бурычлары һәм максатчан күрсәткечләре, сроклары һәм этаплары

Җирлек территориясендә җирләрдән файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль сәясәтнең төп принциплары булып түбәндәгеләр тора: Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегенең законлылыгы һәм ачыклыгы, хисап бирүе һәм контрольдә булуы, нәтиҗәлелеге.

Муниципаль программаның максаты булып җирләрне һәм туфракны пычратуны, ярлыландыруны, деградацияләүне, бозуны, юк итүне һәм җирләргә һәм туфракка башка тискәре йогынтыны булдырмау һәм ликвидацияләү, шулай ук җирләрне рациональ файдалануны, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә туфракның уңдырышлылыгын торгызу һәм җирләрне яхшырту өчен тәэмин итү тора.

Куелган максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- куллану эшчәнлеген оптимальләштерү;
- җирләрдән рациональ файдалануны һәм саклауны оештыруның нәтиҗәлелеген арттыру;
- яшел үсентеләрне саклау һәм торгызу;

- жирләрне инвентаризацияләү.

Җирләрне инвентаризацияләү җирләрне деградацияләү, пычрату, чүпләү, бозуны, хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысын булдырмау, кулланылмаган, рациональ кулланылмаган яки максатчан билгеләнеше буенча кулланылмаган һәм рөхсәт ителгән файдалану төре буенча кулланылмаган җир кишәрлекләрен, җирләрнең башка характеристикаларын ачыклау максатыннан башкарыла.

Әлеге программаны тормышка ашыру җирдән файдалануны тәртипкә салуга; әйләнешкә яңа җир кишәрлекләрен кертүгә; авыл җирлегенең инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыруга, нәтиҗәдә икътисадны үстерүгә, җирләрне нәтиҗәле файдалануга һәм саклауга ярдәм итәчәк.

Программа чараларын үтәү нәтиҗәсендә тәэмин ителәчәк:

1) торак пунктларны төзекләндерү;
2) җирләрнең сыйфат характеристикаларын яхшырту;
3) җирләрдән нәтиҗәле файдалану.

Программаны тормышка ашыру срогы – 2021-2023 еллар.

## 3. Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа кысаларында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклау һәм алардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру чаралары планлаштырылган.

| N | Чаралар исеме | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | Башкаручы | Үтәү вакыты | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Чокырларның өске катламын ныгыту | Оешмаларның, шәхси затларның, җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 2. | Гомумтаралган файдалы казылма карьерларына инвентаризация үткәрү. Күрсәтелгән карьерларны конкрет оешмаларга беркетү. Аларны рекультивацияләү проектларын эшләү. | - | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2023 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 3. | Карьерларны рекультивацияләү | Оешмаларның, шәхси затларның, җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Карьераларны кулланучылар | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 4. | Шәхси буаларны, башка гидротехник су объектларын ачыклау һәм әлеге корылмаларны конкрет милекчеләр тарафыннан тикшерү | - | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2023 | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Җирдән файдалану, линия корылмалары объектлары, юл челтәре, чикләнгән файдалану җирләре, сыйфат күрсәткечләре белән җирләрнең бердәм банкын формалаштыру һәм алып бару | - | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2023 | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 6. | Мусабай-Заводавыл җирлегенең торак пунктлары территорияләрен төзекләндерү һәм яшелләндерү | | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | Даими | Башкарма комитет җитәкчесе |
| 7. | Авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре үсүдән саклау буенча чаралар үткәрү һәм зарарлы организмнардан саклау | Җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |
| 8. | Деградациягә, пычратуга, чүпләнүгә, хуҗалык эшчәнлегенең башка тискәре (зарарлы) йогынтысына дучар ителгән җирләрне яхшырту һәм торгызуны тәэмин итү | Җирдән файдаланучыларның үз акчалары | Җирләрнең урнашу урыны буенча | Даими | Оешма җитәкчеләре, шәхси затлар |